СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

__26.05.2021___ Баулы шәһәре № _55____

Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр тапшыру һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турындагы аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 30 июненә кадәр, Татарстан Республикасының «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, Татарстан Республикасының «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче гражданнар, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, Татарстан Республикасының «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнар (Татарстан Республикасының «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән вазыйфаларны, аларга билгеләнгәндә гражданнар керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш; муниципаль хезмәткәрләр аларны Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә биләгән очракта, аларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының

керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш - Татарстан Республикасының «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар исемлеге нигезендә – аларга билгеләнгәндә гражданнар керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында; аларны биләгән затлар үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш, әлеге Исемлек Баулы муниципаль районы Советының 2014 елның 11 декабрендәге «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасы керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 239 номерлы карары белән, Баулы муниципаль районы Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 238 номерлы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау хакында» карары, Баулы муниципаль районы башлыгының 2020 елның 27 гыйнварындагы 6 номерлы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының коррупция куркынычларына бәйле вазыйфалары исемлеген раслау турында» карары белән расланган, алар нигезендә, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче гражданнар, Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча тапшырыла торган белешмәләр белән бергә үзләренә, ирләренә

(хатыннарына) һәм балигъ булмаган балаларына караган цифрлы финанс активлары, цифрлы хокуклар, бер үк вакытта цифрлы финанс активларын һәм башка цифрлы хокукларны, утилитар цифрлы хокукларны һәм цифрлы валютаны (алар булганда) үз эченә алган цифрлы финанс активлары турында хәбәрнамәләр тапшыра дип расларга («Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указына 1 нче кушымта нигезендә).

2. Баулы муниципаль районы Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 239 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә (Баулы муниципаль районы Советының 2015 елның 20 апрелендәге 260 номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 241 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), 7 нче пунктның “в” пункчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

« в) үзенең, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре), цифрлы финанс активлары, хисап чорында цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында.».

3. Баулы муниципаль районы Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 2389 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан Баулы муниципаль районы Советы карары белән расланган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә 6

нче пунктның “в” пункчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

« в) үзенең, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре), цифрлы финанс активлары, хисап чорында цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алудан чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми керемennән артып китсә һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында.»;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин